ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 29 гыйнвары №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталарга ярашлы рәвештә 8 370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин исемендәге поселок, Совет урамы, 26 йорт - административ бина, Совет урамы, 28 йорт - СДК бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк урам, 9 йорт - СДК бинасы, Үзәк урам, 15 йорт - мәктәп бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районының
«Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Иванова

1нче кушымта

Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының«Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтләр бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 163,95 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка китерү | 1 590,33 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3 615,92 |
| Барлыгы | **8 370,20** |

2нче кушымта

Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Җирләү эше турында» ФЗ-8 12 статьясы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтләр бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гәүдәне төрү | 1 044,11 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 119,84 |
| 4. Мәрхүмнең гаүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 590,33 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3 615,92 |
| Барлыгы | **8 370,20** |

---